| | | |
|---|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ БАВЛИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАУЛЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

29.08.2025 ел Баулы шәһәре №110

Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының "Баулы муниципаль районы территориясендә административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген раслау хакында" 2025 елның 24 гыйнварындагы 7 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Татарстан Республикасының аерым закон актларына балигъ булмаганнарга автомобиль бензинын сатуны чикләүне билгеләү өлешендә үзгәрешләр кертү турында» 2025 елның 23 июлендәге 53-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын, «Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексына һәм «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген билгеләү буенча, Татарстан Республикасының дәүләт вәкаләтләрен бирү хакында» Татарстан Республикасы Законының 1 статьясына үзгәрешләр кертү турында» 2025 елның 25 июнендәге 46-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын үтәү йөзеннән, Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР ИТӘ:

1. Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының "Баулы муниципаль районы территориясендә административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген раслау хакында" 2025 елның 24 гыйнварындагы 7 номерлы карарына (2025 елның 5 мартындагы 25 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1 пунктта:

- «2.21.,» санынан соң «2.22.,» саннары белән тулыландырырга;

- «3.14.-3.17.,» саныннан соң «3.19.,» саннары белән тулыландырырга;

Баулы муниципаль районы территориясендә административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзергә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлегендә (карарга кушымта):

- «2.21 статья. ТР КоАП Режим (база әзерлеге дәрәҗәсе) кысаларында чараларны гамәлгә ашыруны күздә тота торган Татарстан Республикасы норматив-хокукый актлары таләпләрен үтәмәү» юлыннан соң түбәндәге эчтәлекле юллар өстәргә:

| | |
|---|---|
| «2.22. статья ТР КоАП Автомобиль бензинын балигъ булмаганнарга ваклап сатуны чикләүне үтәмәү | - Баулы муниципаль районы башкарма комитетының икътисад һәм территориаль үсеш бүлеге начальнигы һәм әйдәүче белгече<br><br>»; |

- «3.17 статья. ТР КоАП Транспорт чараларын яшелләндерелгән территорияләрдә, хайваннар йөртү өчен балалар һәм спорт мәйданчыкларында, шулай ук йорт яны территориясендә урнашкан хуҗалык мәйданчыкларында урнаштыру» юлыннан соң түбәндәге эчтәлектәге юл өстәргә:

| | |
|---|---|
| «3.19 статья. ТР КоАП Җирле әһәмияттәге автомобиль юлларыннан файдалану тәртибенә карата таләпләрне бозу | - Баулы муниципаль районы башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеге баш белгече һәм әйдәүче белгече;<br>- Баулы муниципаль районы башкарма комитетының җәмәгать тәртибен саклау һәм балигъ булмаганнарның хокукларын яклау бүлеге әйдәүче белгечләре». |

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе Д.Л. Бакиров